ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 502-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Ш.Ш. Яһудин тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 502-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 23 ноябре
№ 2247-VI ДС

проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутаты
Ш.Ш. Яһудин тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

**Татарстан Республикасы Законы**

**1 статья**

«Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» 2012 елның 2 ноябрендәге 73-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 11 (I өлеш); 2014, № 1 – 2, № 12 (II өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш); 2022, № 17 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 56 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 9 статьяның 2 өлешендә «Адвокатлар» сүзеннән соң «һәм нотариуслар» сүзләрен өстәргә;

2) түбәндәге эчтәлекле $11^1$ статья өстәргә:
«$11^1$ статья. **Нотариуслар тарафыннан түләүсез юридик ярдәм күрсәтү**

1. Нотариуслар Федераль законда һәм әлеге Законда каралган очракларда һәм тәртиптә гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтә.
2. Татарстан Республикасында дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасы эшчәнлегендә нотариусларның катнашуын оештыру Татарстан Республикасы Нотариаль палатасы тарафыннан башкарыла.
3. Дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасы кысаларында нотариуслар тарафыннан түләүсез кылынган нотариаль гамәлләр өчен түләүне компенсацияләү Федераль законда билгеләнгән тәртиптә вәкаләтле орган тарафыннан гамәлгә ашырыла.»;

3) 12 статьяның 3 өлешендәге 2 өлешенә түбәндәге эчтәлекле «д» пунктчасы өстәргә:
«д) ятим балаларның, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның, ятим балалар арасыннан һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларның варислык хокукларын яклау турында;»;

4) 18 статьяның 2 өлешендә «компенсацияләүгә» сүзеннән соң «, дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасы кысаларында нотариуслар тарафыннан түләүсез кылынган нотариаль гамәлләр өчен түләүне компенсацияләүгә» сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

Әлеге Закон 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына аңлатма**

Закон проекты «Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» 2012 елның 2 ноябрендәге 73-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын «Россия Федерациясендә түләүсез юридик ярдәм турында» Федераль законга һәм «Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимият оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 44 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 10 июлендәге 325-ФЗ номерлы Федераль законга (алга таба – 325-ФЗ номерлы Федераль закон) кертелгән үзгәрешләргә туры китерүгә юнәлдерелгән, бу федераль закон 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

325-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгәнчә, дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасы кысаларында нотариуслар дәүләт юридик бюроларының һәм адвокатларның, дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасында катнашучылар буларак, судларда, дәүләт органнарында һәм муниципаль органнарда, оешмаларда гражданнар мәнфәгатендә эш итүенә ышанычнамәләрне түләүсез таныклый. Күрсәтелгән очракта гражданнар нотариусларга адвокатлар йә дәүләт юридик бюролары белән төзелгән килешүне күрсәтергә тиеш.

325-ФЗ номерлы Федераль законга кертелгән үзгәрешләр «Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» 2012 елның 2 ноябрендәге 73-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12 һәм 18 статьялары белән җайга салына торган нигезләмәләргә кагыла. Шуңа бәйле рәвештә аларга да тиешле үзгәрешләрне кертү таләп ителә.

Закон проекты ике статьядан тора.

Закон проектының 1 статьясы «Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законына алда бәян ителгән үзгәрешләрне үз эченә ала.

2 статья закон проектының үз көченә керү тәртибен җайга сала: ул 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керәчәк.

**«Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законы кабул ителүгә бәйле рәвештә үз көчен югалткан дип танылырга, туктатылырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы кабул ителүгә бәйле рәвештә «Татарстан Республикасы территориясендә түләүсез юридик ярдәм күрсәтүнең дәүләт системасы катнашучылары хезмәттәшлеге тәртибен раслау турында» 2013 елның 24 маендагы ПУ-444 номерлы Татарстан Республикасы Президенты Указына үзгәрешләр кертү таләп ителә.

**«Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында»Татарстан Республикасы законы проектын**

# ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ

«Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында «Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты нигезендә нотариусларның дәүләт түләүсез юридик ярдәм күрсәтү системасы кысаларында кылынган гамәлләре өчен түләүне компенсацияләү Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәсе булып тора, аны финанслау тиешле елга Татарстан Республикасы бюджетыında каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә башкарыла.